**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**АТНИНСКИЙ РАЙОННЫЙ**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
422750, село Большая Атня, улица Советская,

дом 38

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘТНӘ РАЙОНЫНЫҢ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
422750, Олы Әтнә авылы, Совет урамы.,

38нче йорт

Тел./факс: 8(84369)21020, E-mail: atnya@tatar.ru, сайт: atnya.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

30.12.2019 ел — № 391

“Татарстан Республикасы
Әтнә муниципаль районында
2020-2023елларга «Мәктәпкәчә
белем бирүне үстерү"турындагы
максатчан программаны раслау турында”

Әтнә муниципаль районында мәктәпкәчә белем алуга дәүләт гарантияләрен тәэмин итү максатларында, карар бирәм:

1. «Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районында 2020-2023 елларга мәктәпкәчә белем бирүне үстерү» максатчан программасын расларга (1 нче кушымта).

2. Татарстан Республикасы Әтнә районы башкарма комитеты җитәкчесенең 2019 елның 21 гыйнварындагы 15 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Балалар бакчалары мөдирләренә район максатчан программасын тормышка ашыру планын эшләргә.

4. Әлеге программаның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Әтнә районы Башкарма комитетының МКО «мәгариф бүлеге» башлыгына йөкләргә.

Җитәкче — А.Ф. Каюмов

Әтнә районы
башкарма комитеты җитәкчесенең
30.12.2019 ел. 391номерлы
карары белән расланган

# “2020-2023 елларга Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районында мәктәпкәчә белем бирүне үстерү” район максатчан программасы

**Олы Әтнә, 2019**

**“2020-2023 елларга Татарстан Республикасы**
**Әтнә муниципаль районында мәктәпкәчә белем бирүне үстерү”**
**район максатчан программасы**
**ПАСПОРТЫ**

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | “2020-2023 елларга Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районында мәктәпкәчә белем бирүне үстерү” |
| Муниципаль заказчы – Программа координаторы | Әтнә район башкарма комитеты |
| Программаның муниципаль заказчысы | ТР Әтнә районы Башкарма комитетының “Мәгариф бүлеге» муниципаль казна учреждениесе” |
| Программаны Эшләүче | ТР Әтнә районы Башкарма комитетының “Мәгариф бүлеге» муниципаль казна учреждениесе” |
| Программаны башкаручылар | ТР Әтнә районы Башкарма комитетының “Мәгариф бүлеге» муниципаль казна учреждениесе”<br>- Әтнә муниципаль районының муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре |
| Программаның максаты: | Муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмалары челтәрен үстерү хисабына мәктәпкәчә белем алу мөмкинлеген тәэмин итү |
| Программаның бурычлары | 1. Ведомство буйсынуындагы учреждениеләр эшчәнлеген (мәктәпкәчә белем бирүне оештыру буенча хезмәтләр күрсәтүне) тәэмин итү, шул исәптән муниципаль бюджет учреждениеләренә субсидияләр бирү.<br>2. Муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында өстәмә урыннар булдыру |
| Программаны тормышка ашыру вакыты | 2020 - 2023 еллар. |
| Программаны финанслау | Программаны финанслау хисабына башкарыла:<br>- җирле бюджет акчалары;<br>- федераль бюджет акчалары |
| Программаның соңгы нәтиҗәләре | 1. 2023 елга карата мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында урыннар кытлыгын бетерү 1% тәшкил итә.<br>2. Мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында тәрбияләнүчеләрнең федераль дәүләт белем бирү стандартларына туры килә торган программалар буенча белем алучы мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында тәрбияләнүчеләрнең чагыштырма күләме-2023 елга 100 %. |

## I. Әтнә районының мәктәпкәчә белем бирү системасының торышы.

Әтнә муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү системасы мәктәпкәчә белем бирүнең һәркем өчен мөмкин булган дәүләт гарантияләрен тәэмин итү максатларында эшли, бу исә халыкның мәктәпкәчә белем бирү хезмәтләренә булган ихтыяҗын канәгатьләндерү бурычларын тормышка ашыруны күздә тота. Әтнә районының мәктәпкәчә белем бирү системасын 13 мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе һәм 1 башлангыч мәктәп - балалар бакчасы тәшкил итә. 2020 елның 1 гыйнварына мәктәпкәчә белем бирүне колачлау 62,7 % тәшкил итә. Алдагы программаны гамәлгә ашыру барышында әлеге күрсәткечне 6,7% ка арттыруга ирешкәннәр. 2014 елда Түбән Көек һәм Коморгуҗа авылларында һәм 2018 елда Ташчишмә авылында балалар бакчалары ачылу белән Әтнә муниципаль районында мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләреннән башка авыл җирлекләре калмады.

Шуның белән бергә, районда мәктәпкәчә белем бирү хезмәтләренә ихтыяҗ бар. Балалар бакчаларына чират «Электрон балалар бакчасы» АИСда җайга салына. 2019 елның 1 гыйнварына 138 бала чиратта тора бала. Район үзәгендә урнашкан Олы Әтнә балалар бакчасында (89 кеше) чиратта торучыларның күбесе.

Барлык белем бирү учреждениеләре белем бирү эшчәнлегенә сроксыз лицензиягә ия. Мәктәпкәчә белем бирүдә күрсәтелә торган хезмәтләргә анализ ясау, нигездә, Н.Е.Веракса, Т.С.Комарова, М.А.Васильева редакциясе астында укыту-тәрбия процессының «Туганнан мәктәпкә кадәр» якынча төп белем бирү программасы нигезендә алып барылуын күрсәтә. Мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен учреждениеләрдә өстәмә белем бирү хезмәтләре күрсәтелми. Инновацион белем бирү программаларын үзләштерү һәм гамәлгә кертү процессы акрын бара. Мәктәпкәчә белем бирүнең яңа заманча сыйфатына ирешү өчен яңа буынның үсеп килүче программаларын һәм технологияләрен практикага кертергә кирәк. Мәктәпкәчә һәм башлангыч белем бирү баскычларының дәвамчанлыгы тәэмин ителә. Районның мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә 5-6,5 яшьлек, балалар бакчаларына йөрмәүче балаларга мәктәп алды әзерлеге оештырылган. Мәктәп алды белем бирү учреждениеләрендә балаларны колачлау 100% тәшкил итә.

Мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре педагогик хезмәткәрләренең кадрлар составын анализлау күрсәткәнчә, белгечләрнең 83,4 % ы югары белемле (2013 елда - 52%), 16,6 % - урта һөнәри белемле. 6 мәктәпкәчә белем бирү учреждениесендә музыка җитәкчеләре, 1 мәктәпкәчә белем бирү учреждениесендә логопед һәм физкультура буенча инструктор эшли.

Бүгенге көндә мәктәпкәчә белем бирүнең сыйфатын тәэмин итү өчен әлеге учреждениеләрдә эшләүче педагогларның һөнәри дәрәҗәсе мөһим. Мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре җитәкчеләренең һәм педагогик персоналының квалификациясен күтәрүгә аерым игътибар бирергә кирәк.

Соңгы 5 ел эчендә Күәм балалар бакчасы, Кышлау башлангыч мәктәп-балалар бакчасы, Олы Мәңгәр балалар бакчасы биналарына капиталь ремонт ясалды, Кушар балалар бакчасы, Күңгәр балалар бакчасы биналары төзелде. Шуның белән бергә, Күлле-Киме балалар бакчасы, Олы Әтнә балалар бакчасы, Дусым балалар бакчасы, Түбән Бәрәскә балалар бакчасы биналарын ремонтлау таләп ителә. Мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрен матди-техник яктан тәэмин итү федераль дәүләт белем бирү стандарты таләпләренә тулысынча туры килми. Түбән Бәрәскә балалар бакчасы, Ташчишмә балалар бакчасы һәм Күнгәр балалар бакчасы Интернет челтәренә тоташтырылмаган.

## II. Программаның максатлары һәм бурычлары.

Программаның максаты – Әтнә муниципаль районында сыйфатлы мәктәпкәчә белем бирүне тәэмин итү.

Максатка ирешү өчен түбәндәге бурычларны хәл итәргә кирәк:

1. Ведомство буйсынуындагы учреждениеләр эшчәнлеген (мәктәпкәчә белем бирүне оештыру буенча хезмәтләр күрсәтүне) тәэмин итү, шул исәптән муниципаль бюджет учреждениеләренә субсидияләр бирү.

2. Мәктәпкәчә белем бирү муниципаль мәгариф оешмаларында өстәмә урыннар булдыру.

Программаны тормышка ашыруның соңгы нәтиҗәләренең төп күрсәткечләре булып тора:

- мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында урыннар кытлыгын бетерү;

- мәктәпкәчә белем бирүнең федераль дәүләт белем бирү стандартларына туры килә торган программалар буенча белем алучы мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында тәрбияләнүчеләрнең чагыштырма күләме - 2023 елда – 100 % ;

Программаны тормышка ашыру вакыты – 2020-2023 елларда дәүләт программасын гамәлгә ашыру чоры дәвамында.

## III. ПРОГРАММАНЫҢ ТӨП ЧАРАЛАРЫ ТУРЫНДА КЫСКАЧА ТАСВИРЛАМАСЫ

“Ведомство буйсынуындагы учреждениеләрнең мәктәпкәчә белем бирү эшчәнлеген тәэмин итү (хезмәт күрсәтү), шул исәптән муниципаль бюджет учреждениеләренә субсидияләр бирү” бурычын үтәү өчен түбәндәге төп чараларны гамәлгә ашырырга кирәк:

1. Муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә белем алуга гражданнарның хокукларын гамәлгә ашыруны тәэмин итү.

Әлеге чараны гамәлгә ашыру гражданнарга һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә белем бирү буенча мәктәпкәчә белем бирү оешмалары эшчәнлеген тәэмин итүгә юнәлдерелгән.

2. Әтнә муниципаль районы мәгариф оешмаларында мәктәпкәчә белем бирүнең федераль дәүләт мәгариф стандартларын гамәлгә ашыру.

Әлеге чараны тормышка ашыру мәктәпкәчә белем бирүнең федераль дәүләт стандартын гамәлгә ашыру буенча муниципаль белем бирү оешмаларының эшен оештыруга, федераль дәүләт белем бирү стандартлары таләпләрен исәпкә алып, федераль дәүләт белем бирү стандартларын гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыруга, төп белем бирү программаларын эшләү, мәктәпкәчә белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең квалификациясен күтәрүгә һәм һөнәри әзерләүгә юнәлдерелгән.

“Мәктәпкәчә белем бирү муниципаль белем бирү оешмаларында өстәмә урыннар булдыру” бурычын үтәү өчен түбәндәге төп чараларны гамәлгә ашырырга кирәк:

1. Районда мәктәпкәчә белем бирү системасын модернизацияләү.

## IV. ПРОГРАММАНЫҢ АХЫРГЫ НӘТИҖӘЛӘРЕН ФАРАЗЛАУ

| № | Күрсәткеч атамасы, үлчәү берәмлеге | Башкаручы (берлектә) | 2020ел. | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1. | Мәктәпкәчә белем бирү оешмаларына чиратны | МКУ “Мәгариф | 3,0 | 2,0 | 1,5 | 1,0 |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | киметү, % | бүлеге” | | | | |
| 2. | Мәктәпкәчә белем бирү оешмалары объектларының тузу дәрәҗәсе, % | МКУ “Мәгариф бүлеге” | 30 | 32 | 35 | 38 |
| 3. | Мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында тәрбияләнүчеләрнең федераль дәүләт белем бирү стандартларына туры килә торган программалар буенча белем алучы мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында тәрбияләнүчеләрнең гомуми саны, % | МКУ “Мәгариф бүлеге” | 100 | 100 | 100 | 100 |

## V. ПРОГРАММАНЫ РЕСУРС БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ (РЕСПУБЛИКА ҺӘМ МУНИЦИПАЛЬ БЮДЖЕТНЫҢ ТӨП АКЧАЛАРЫ, ТӨП ЧАРАЛАР КИСЕЛЕШЕНДӘ, ШУЛАЙ УК ПРОГРАММАНЫ ТОРМЫШКА АШЫРУ ЕЛЛАРЫ БУЕНЧА)

Программаны гамәлгә ашыру өчен бюджет ассигнованиеләре күләме – 249159,2 мең сум тәшкил итә , шул исәптән еллар буенча:

2020 ел ( фараз) - 61323,7 мең сум.;
2021 ел ( фараз) - 62012,6 мең сум.;
2022 ел ( фараз) - 62632,6 мең сум.;
2023 ел (фараз) – 63190,3 мең сум.

| **Финанслау чыганаклары** | **2020** | **2021** | **2022** | **2023** |
|---|---|---|---|---|
| **Ата-аналар взносы** | **16080,3** | **16624,5** | **16790,8** | **16933,7** |
| **Бюджеттан тыш акчалар** | **13,5** | **13,5** | **13,5** | **13,5** |
| **Җирле бюджет** | **45229,9** | **45374,6** | **45828,3** | **46243,1** |

## VI. ПРОГРАММА ЧАРАЛАРЫ ИСЕМЛЕГЕ

| | Эшчәнлегенең төп юнәлешләрен тормышка ашыру чаралары һәм механизмнары | Финанслау чыганаклары (мең сум) | 2020 ел | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел |
|---|---|---|---|---|---|---|

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
|---|---|---|---|---|---|---|
| **1. Мәктәпкәчә белем бирү системасын үстерү** | | | | | | |
| 1. | Педагогларның һәм хезмәт күрсәтүче персоналның хезмәт хакы | МБ | 35471,3 | 35504,6 | 35859,6 | 36218,2 |
| 2. | Мәгариф учреждениеләренең матди-техник базасын ныгыту | МБ | 2315,2 | 23152 | 2338,3 | 2338,3 |
| | | Ата-аналар взносы | 2212,6 | 2212,6 | 2234,8 | 2234,8 |
| 3. | Мөлкәтне карап тоту һәм төзекләндерү буенча шартлар тудыру | МБ | 4739,3 | 4905,4 | 4954,5 | 5004,0 |
| 4. | Балалар куркынычсызлыгын тәэмин итү:<br>- мәктәп биналарын һәм территорияләрен видеокүзәтү системалары белән тәэмин итү;<br>Мәктәп куркынычсызлыгы системаларына хезмәт күрсәтү:<br>АПС,<br>- "хәвеф төймәләре"» | МБ | 470,4 | 470,4 | 475,1 | 475,1 |
| 5. | Мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре челтәрен һәм мәктәпкәчә белем бирү процессын оештыруның яңа формаларын үстерү | МБ | 423,9 | 423,9 | 428,1 | 428,1 |
| 6. | Балалар бакчасы нотариаль хезмәтләре | МБ | 27,4 | 27,4 | 27,7 | 27,7 |
| 7. | Балалар бакчасы белән идарә итү системасын мәгълүмати тәэмин итү | МБ | 46,0 | 46,0 | 46,5 | 46,5 |
| 8. | Мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре педагогларының квалификациясен күтәрү | МБ | 63,9 | 63,9 | 64,6 | 64,6 |
| 9. | Мәктәпкәчә һәм гомуми белем бирү учреждениеләрендә туклану сыйфатын яхшырту | МБ | 635,2 | 660,6 | 667,2 | 673,9 |
| | | Ата-аналар взносы | 13605,7 | 14149,9 | 14291,4 | 14434,3 |
| 10. | Мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренең салым базасын тәэмин итү | МБ | 921,2 | 921,2 | 930,4 | 930,4 |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 11. | Заманча дидактик үстерү уеннары, методик тээмин итү материаллары сатып алу | МБ | 36,0 | 36,0 | 36,4 | 36,4 |
| | | Ата-аналар взносы | 262,2 | 262,0 | 264,6 | 264,6 |
| | | ВБ | 13,5 | 13,5 | 13,5 | 13,5 |
| | МӘКТӘПКӘЧӘ БЕЛЕМ БИРҮ УЧРЕЖДЕНИЯЛӘРЕ | | **61323,7** | **62012,6** | **62632,6** | **63190,3** |
| | Шул исәптән | **Ата-аналар взносы** | **16080,3** | **16624,5** | **16790,8** | **16933,7** |
| | | **ВБ** | **13,5** | **13,5** | **13,5** | **13,5** |
| | | **МБ** | **45229,9** | **45374,6** | **45828,3** | **46243,1** |